# МӘХӘББӘТ ЯҢГЫРЫ



МАРАТ КӘБИРОВ

12+

"ЖАНРЛАР"

Марат Кәбиров

# Мәхәббәт яңгыры

«ЛитРес: Самиздат»
2019

**Кәбиров М.**

Мәхәббәт яңгыры / М. Кәбиров — «ЛитРес: Самиздат», 2019

"Менә тагын урамнарда яңгыр. Менә тагын яңгыр синсез яуа. Яңгыр җиргә сафлык алып килә, яңгырларда тәннәр җиңеләя, сулышларың иркенәеп кала. Иңнәреңә канат үскән кебек, хыял күкләренә талпынасың. Бүген никтер минем җанда – сагыш. Әллә сине юксынудан микән. Син бит миңа якты яңгыр идең. Назга коргаксыган җаныма син җылы яңгыр булып килеп кердең, татлы тамчыларың белән сибелдең дә йөрәгемнең юшкыннарын юдың. Мин сафланып, үзем булып калдым, мәхәббәтле синең тамчылардан рухыма көч, яшәүгә дәрт алдым. Рәхмәт сиңа! Яңгыркаем минем… "

© Кәбиров М., 2019
© ЛитРес: Самиздат, 2019

**1**

Бүлмәдәге хатын–кызлар кайсы язып, кайсы кульязма укып өстәлгә капланып утыралар иде. Таңчулпан гына бер эшкә дә тотына алмады, тып-тып итеп тәрәзәгә сибәләгән яңгыр тамчылары астында, бүген күргән төше хәтеренә килде дә шуны уйлап эт булды. Төш күрдем дип артык исе китә торган кеше дә түгел иде инде югыйсә. Әмма, әллә шул яңгыр тәэсирендә, бүгенге төше тынгы бирмәде. Бер карасаң, күргән төшенең һуш китәрлек нәрсәсе дә юк: аяз көнне яңгыр койды да койды гына, ә ул тукталгач, Таңчулпан белән ниндидер егеттән башка һичберкем дә чыланмаган булып чыкты. Ә бит урам тулы халык иде. Ник берәү дә чыланмады икән?! Аннан соң, боларның барсы да төштә булса да, Таңчулпан ул яңгырны өнендә күргәндәй тоела, хәтта киемнәренең җебенә кадәр су үтеп, ни дәрәҗәдә күшегүен дә хәтерли, юк хәтерли генә түгел, ул аны әле дә үз җанында, үз тәнендә тоя кебек иде… Кулына эш бармаса да ул, тырышып-тырмашып нидер кыйраткан каләмдәшләре алдында тик утырудан кыенсынып, алдындагы кульязмага текәлгән, янәсе бик бирелеп укый инде.

Көтмәгәндә яңгыраган тавыш барсының да башын күтәрде:

– Сәлам, кызлар! Туган илгә хезмәт итәбезме?

Башны күтәрүгә иң тәүдә керүченең бөтен йөзен балкыткан елмаюы күзгә ташланды, бераздан күдрәрәк булып торган коңгырт чәчләре, зифа буй—сыны шәйләнде. Барсы берьюлы күтәрелеп караудан егет үзе дә уңайсызланыбрак калды, ахрысы, ишек янында гына утырган Таңчулпаннан күзләрен тиз генә аерды да, карашын бүлмәдәгеләрнең әле берсенә, әле икенчесенә йөгертте һәм, ниһаять, үзенең ник кергәнен исенә төшергәндәй, урта яшьләрдәге хатынга төбәлде:

– Фәндидә апа, сине сагынып кердем бит мин.

Фәндидәнең күзләрендә мутлык чаткылары күренде:

– Сизеп торам, Искәндәр,– дип елмайды ул,– Мине сагынмый менә бу гүзәлләрне сагынмассың бит инде.

Егет тагы бүлмәдәгеләргә күз йөгертеп чыкты. Кызлар чынлап та гүзәл иде. Әле яңарак кына беренче баласын табып декреттан килгән Алсу да, яшь кенәдән баш-аягы белән дингә чумган Хәдичә дә – һәрберсе үзенчә матур, үзенчә соклангыч иде. Шулай да Искәндәр карашларын Таңчулпанда озаграк тотты. Ә үзе шул халәтеннән уңайсызлангандай Фәндидәнең каршысына ук килеп басты.

– Безнең вечный любовь бит, әйме, Фәндидә апа! – Карашлары янә Таңчулпан ягына омтылды, әмма егет вакытында тыелып өлгерде,– Фәндидә апа, мин бит синең ярдәмеңә мохтаҗмын. Биреп тор әле шул Сак-Сок китабын.

– Менә сиңа кирәк булса,– дип елмайды Фәндидә апа,– Любовь-любовь дип ымсындырды да хәзер Сак-Сок имеш… Ни хаҗәте тиде инде аның сиңа?

– Бик кирәк иде шул, Фәндидә апа.– Фәндидә апа өстәл тартмасындагы китапка үрелгәндә, Искәндәр Таңчулпанга күз ташлады, карашлары очрашты да кыз керфеге түбән кадалды, – Кавыштырам мин ул Сак-Сокларны.

Искәндәр китабын алды да рәхмәт әйтеп чыгып китте.

– Тиленәнеп йөри инде,– дип куйды Фәндидә,– Тагын берәр мөгез чыгарырга уйлый торгандыр.

Фәндидәнең сүзләре үз итеп, яратып әйтелсә дә Таңчулпан аның «тиленәнеп» дигәнен өнәп бетермәде. Шулай да каршы килеп сүз әйтергә кыймады, «иштең ишәк чукмарын» дигәндәй, кашларын гына сикертеп куйды. Алсу да шундыйрак фикердә булган, ахры:

–Аңа ничек йөрсә дә килешә,– диде ул, хыялый бер соклану белән,– Искәндәр бит ул! Нинди халәттә булса да – Искәндәр.

Таңчулпан Алсуга рәхмәтле караш ташлады, шул ук вакытта үзенең кыюсызлыгына үзе үкенебрәк тә калды – Таңчулпан да нәкъ шулай уйлаган иде бит, ул да әйтә алган булыр иде, тик әйтмәде, әйтә алмады, кыюлыгы җитмәде. Ә Алсу Казанда укып, бик күп күренекле шәхесләр

белән аралашып, Казан һавасын сулап кайткан кыз, бер дә өркеп–куркып тормады, әйтергә теләгәнен ачты да салды. Аның сүзенә, әлбәттә, Фәндидә апаның исе дә китмәде инде. Елмая биребрәк бүлмәдәге яшьләрнең әле берсенә, әле икенчесенә күз йөгертеп чыкты да балаларын тиргәгән ана сыманрак итеп әйтеп куйды:

– Шулай бозып бетерәсез инде.

Шуның белән сүз бетте. Искәндәр турында сөйләшкәннәрен тагы да озак тыңларга әзер иде Таңчулпан, тик сүзне дәвам иттерер өчен ни дә булса әйтергә батырлыгы җитмәде. Бераздан бүлмәдәгеләр янә бирелеп эшкә чумды, тик Таңчулпан гына тагын бер нәрсәгә дә кереп китә алмый иза чикте, баштарак үзен кыюсызлыгы, булдыксызлыгы өчен битәрләп бер булса, соңрак бүген төнлә күргән төшен кабат исенә төшерде. Бу юлы төшенең бөтен вак–төякләрен күзалларга омтылды, һәм чынлап та, тырыша торгач, ул аны бөтен нечкәлекләре белән, төсле кино карагандай итеп яңадан күз алдына бастырды, кайсы бер моментларын нәкъ кинодагы кебек итеп, кабат кабат әйләндерде, һәм үзенең әлеге төшне ник оныта алмавын аңлады да бөтен дөньясын яшен көйдереп үткәндәй тоелды…

Ә урамда яңгыр коя иде.

Таңчулпанның бу редакциягә эшкә килүенә берничә ай гына әле. Башта елга якын ярты ставкада гына йөрде, редакция халкын танып белсә дә артык якын аралаша алмады, хәзер менә Фәндидә апа әйтмешли, утырып эшли башлагач, барсын да күреп белә, холык–фәләнен дә, кемнең нәрсәгә сәләтле икәнен дә чамалый кебек. Кечкенәдән кулына каләм алып балалар басмасында шактый ук танылып өлгергән кыз өчен, тәүдәрәк, редакциядә тик талантлы каләмкярләр генә эшлидер, шулар арасында тиң булып йөрү зур мәртәбәдер сыманрак тоела иде. Хәзер ул монда да сәләте белән әллә кая китәлмәгәннәр барлыгын белә инде, шулар арасында үзенең бик үк төшеп калганнардан түгеллеген дә чамалый. Моны башкалар да тоя, ахры, Таңчулпанга иң четерекле мәсьәләләрне дә ышанып тапшыралар, ихтирамнары да, игътибарлары да сизелеп тора. Икенчедән, сәләтләре төрлечә булса да журналист халкы бер–берсенең кешелеклелегенә ныграк бәя бирә, осталык та, тәҗрибә дә вакыты белән килә, ә кешелек сыйфатың чамалы икән, гафу ит, бу инде мәңгегә – бөкерене кабер генә төзәтә. Бу мөнәсәбәт белән тулысынча килешеп җитмәсә дә Таңчулпан бик каршы да төшми. Дөресен генә әйткәндә, ул әле чынлап торып бәхәсләшергә, ниндидер мәсьәләләрдә үз карашын белдерергә бик өйрәнеп тә җитәлми, үзен түбәнгәрәк куя, ахрысы. Яшьрәк булсалар да Алсу белән Хәдичә бу җәһәттән күпкә кыюрак, хәер, алар коллективта яңа хезмәткәр түгел шул, монда үз кеше булып беткәннәр, тәҗрибәләре дә зур.

Тәҗрибәле журналистлар хәтсез эшли бу гәзиттә. Фәндидә апа шундыйларның берсе. Аннан башка да күпләр бар – әллә нинди дәүләт бүләкләре ияләре, танылган язучылар. Барсы да редакция кануннарына буйсынып, «мин–мин»леген артык күрсәтмичә генә эшли һәм яши бирә. Бер нинди шартлылыкны да, бер нинди кануннарны да бар дип белми торган кеше дә юк түгел. Монсы инде Искәндәр була. Ул беркайчан да вакытында эшкә килми, вакытында кайтып китми, көне буена бүлмә саклап утырмый. Килгән кунакларын хәмер белән дә сыйларга, алар белән бергә үзе дә сыйланырга мөмкин. Әлбәттә, аны тиргәп тә, премияләрен кисеп тә торалар, ләкин Искәндәрнең моңа бик исе китми, ул үзенчә яши бирә. Аның урынында башка берәү булса, эштән куу белән куркытырлар һәм куарлар да иде. Тик Искәндәрне моның белән алдырып булмый. Аны моңа кадәр куып та караганнар инде, болай гына түгел, статья белән куганнар, тик берничә айдан баш мөхәррир кабат чакырып алырга мәҗбүр булган. Искәндәр нәкъ шул вакытта үз шартларын куеп, тәртипсезлеген законлаштырып килгән, диләр. Башта ул Таңчулпанга бик тәкәббер, кырыс бәндә булып тоелган иде. Үз–үзен тотышында һавалану, хәтта бераз мактану да бар сыман күренгән бу яшь кешегә карап ул: «Монсы тагын ниндирәк кош инде?!»—дип уйлап та куйган иде хәтта. Бер–ике мәкаләсе гәзиттә күренүгә үк үзен әллә кемгә санап йөрүче «йолдыз»га охшаткан иде ул аны. Тик кем икәнен, дөресрәге, исемен белү белән, хаталануын аңлады. Искәндәр бер ничә шигырь китабы чыгарып танылу тапкан, роман,

повестьлары гәзит–журналларда басылып торган язучы иде. Әсәрләрен Таңчулпан үзе дә, ире Тәлгать тә бик яратып укыйлар, аны әлеге чорның иң талантлы язучыларыннан исәплиләр иде.

Әле Искәндәрне якын күреп, бар күңеле белән аның яклы булып утыруы да шул талантын бәяләүнең бер галәмәте генә иде. Һәрхәлдә, Таңчулпан үзе шулай уйлады. Хәер, башкача булуы мөмкин дә түгел иде инде. Ни генә әйтсәң дә, икесенең дә үз гаиләсе, балалары бар…

Гаилә турында уйлавына, бүгенге төше кабат хәтеренә килде. Әллә нинди сәер төш булды әле ул, онытылмый да, тынгылык та бирми. Таңчулпан янә бер тапкыр аны күздән кичерде.

Ниндидер кояшлы якты көн, имеш. Таңчулпан күкрәгенә сыймас шатлыгы бар сыман, чәчәкле болын буйлап канатланып йөгереп килде дә көтмәгәндә әрәмәлеккә кереп юлыкты, агачлар арасында сузылган үрмәкүч авына эләгеп туктап калды. Пәрәвез җепселләреннән ычкынырга теләп чәбәләнергә тотынды, тик аның саен ныграк урала барды, ә җепселләр мизгел эчендә калынаеп, котылып булмаслык арканга әверелде. Ул арканнар кояш нурында төрле төскә кереп балкый, бу матурлык ничектер үзенә тарта һәм бөтен җаның-тәнең ирекkә чыгуны таләп итсә дә, арканнар назыннан ычкынасы килми, анда син үзеңне хәвефсезрәк тойган кебек буласың. Менә шундый сәер халәттә озак бик озак бәргәләнде Таңчулпан. Кайчагында, агачлар арасыннан, ире Тәлгатьнең йөзе күренгәндәй булып, аңа ялварды:«Кадерлем, коткар мине мондый халәттән! Зинһар, коткар!» Тик бер нинди дә җавап ишетелмәде… Ә бераздан яшен яшьнәде. Кулында яшен шарлары уйнатып бер егет пәйда булды. Ул егетнең карашыннан ук теге арканнар әзелеп, эреп юкка чыкты һәм Таңчулпан, мәңгелек тамуг газапларыннан котылган кеше сыман аңа иярде. Тиздән яңгыр коярга тотынды. Чиләкләп койды яңгыр, чыланмаган бер генә урынны да калдырмады, тәннең һәрбер күзәнәгенә үтеп кергән сыман тоелды ул, күзәнәкләрнең эчендә дә чиләкләп яңгыр коядыр, бу яңгыр мәңге туктамастыр сыман тоелды. Тик ул туктады. Яңгыр тукталу белән алар ниндидер шәһәр урамында булып чыктылар. Якты шәһәр, ниндидер сихри, әкияти шәһәр иде бу, күгендә көләч кояш елмая, ә асфальт буйлап, көчле бер дулкын булып гөрләвекләр ага. Кинәт Таңчулпан бер нәрсәгә игътибар итте – теге егет белән икесеннән башка берәү дә чыланмаган иде. Ни өчен шулай икәнен сорау белән, ул уянып китте. Ә егетнең җавабын инде өнендә ишетте:«Бу мәхәббәт яңгыры…»

Әлеге төше мәгънәсез бер саташу кебек тоелса да Таңчулпан аның тәү карашка ярылып ятмаган асылын табарга тырышты. Ни өчен оныта алмавын ул инде күңеле белән тоемлый иде. Әйе, аны арканга әверелеп киткән үрмәкеч авыннан коткаручы егетнең кем икәнен ул белә, аның Искәндәргә тамчы судай охшаган булуын бер мизгелгә дә хәтереннән чыгара алмый, шул ук вакытта бу хакта кычкырып әйтергә түгел, ачыктан-ачык уйларга да курка, бу турыда уйлау үзе генә дә баш китәрлек гөнаһ кебек тоела иде. Ләкин уйламыйча да булдыра алмый, ул егетнең төс-кыяфәте генә түгел, тавышы да тач Искәндәрнеке иде бит. Төшендә әйтелгән: «Бу – мәхәббәт яңгыры» – дигән сүзләре белән аның бүген кереп «Сак-Сок» бәетен соравы арасында да, хәтта Таңчулпанга караш ташлап:«Кавыштырам мин аларны» – диюләренә кадәр, ниндидер яшерен сер, яшерен бәйләнеш бардыр сыман тоела иде. Бу очраклы хәл генә түгелдер, очраклылык болай ук була алмыйдыр, бу – күкләр ихтыяры белән генә була ала торган гайре табигый хәлдер сыман иде.

Үз уйларының һаман саен тирәнгәрәк сөйрәвеннән курыккан Таңчулпан урыныннан торып электр чәйнүген кушты:

– Бер юньле эш чыкмый әле. Чәй эчеп карарга кирәк.

– Мин дә шуны уйлап тора идем, – дип елмайды Алсу, – Баядан бирле бер сүз язалмадым. Искәндәр дөрес әйтә ул:«Язучы ике генә очракта өстәл артында утырырга тиеш: я башында юньле фикер булса, я табында ашы булса. Әлбәттә, җилкәсендә башы булса…»

Фәндидә кызларга елмаеп күз йөгертте:

– Искәндәрне телдән дә төшерми башладыгыз әле. Хәерлегә булсын.

– Ә нигә?.. Үзебезнең даһи бит.

– Һәр даһида аз гына Иблислек кушылган була,– дип елмайды Фәндидә, – Яратып кына әйтәм, кызлар, сак булыгыз.

Таңчулпан бая чәй эчкәннән юылмый калган савыт-сабаны алып, юыну бүлмәсенә ашыкты. Искәндәр хакында сөйләшү аңа рәхәт тә, куркыныч та иде. Аннан соң, Фәндидә апаның сүзләре ничектер авыр булып ишетелде. Бу юлы Алсуның Искәндәрне яклашуы да ничектер эчен пошыргандай булды, ник гел шуны гына сөйләп тора әле ул? Кеме әле ул аның?

Савыт-саба юып килгәндә каршысына Искәндәр очрады. Таңчулпан ничектер тертләп китте дә адымын тизләтте. Искәндәрнең берәр сүз әйтеп, кызартуыннан курыкты. Тик ул дәшмәде генә түгел, аның ягына борылып та карамады, ул Таңчулпанны бөтенләй күрмәде дә бугай, ул Таңчулпанның дөньяда барлыгын бөтенләй оныткан иде бугай. Моны тоюдан күңеленә авыр булып китте, ул үзен нәрсәгәдер алданган сабый кебегрәк итеп сизде.

Таңчулпан кергәндә бүлмәдәгеләр яңа темага күчкәннәр иде инде.

– Юк, барыбер, шәригать кануннары безнең өчен ничектер сәеррәк инде хәзер,—дип бәхәсне дәвам итте Алсу,– Ир-егетләргә күтәрелеп тә карарга ярамый, имеш. Җәмәгатеңә хыянәт итү – гөнаһ, ансы аңлашыла. Хыянәт бер канунга да сыймый. Ә ирләргә күз салырга ярамый дигәне…

Фәндидә серле генә елмаеп куйды. Ә дин мәсьәләләрендә күпне белгән Хәдичә, җитдилеген җуймыйча үз фикерен алга сөрде:

– Хыянәт – гөнаһ. Ә хыянәт итү турында уй йөртү икеләтә гөнаһ. Чит-ятлар турында хыяллануны ходай тәгалә бер вакытта да кичерми.

Таңчулпан тертләп китте. Ләкин үзен шундук кулга алды. Нинди гөнаһ кылды әле ул? Кем хакында хыял йөртте? Уйларыннан Алсуның каһкаһәле тавышы бүлдерде:

– Димәк, мин, тәүбә-тәүбә, чит ир белән йоклап чыгам икән, мин хыянәт итү турында уйлаудан да бәләкәйрәк гөнаһ кылам булып чыга?!. Димәк, күзеңне четердәтеп йом да, бер нәрсә уйламыйча, очраган беренче ир-атның куенына сикер! Һәм гөнаһтан азат буласың. Мантыйк кайда соң монда?

– Бөтен нәрсә уйдан башлана, – дип бик җитди дәвам итте Хәдичә, – Яхшысы да, начары да. Шуңа күрә, яхшы уйда булганнар начарлык кылмый. Мантыйгы шунда аның.

Мондый фәлсәфи бәхәсләр редакциядә еш була һәм журналистлар аны «фикер чарлау» дип йөртә иде. Башка вакытларда аңа Таңчулпан да кушылып китә, бер кайчан да диярлек уртак фикергә килә алмасалар да, бу үз уйларыңны тәртипкә китерергә булыша. Тик бүгенге тема Таңчулпанга эч пошыргыч булып тоелды, хезмәттәшләре, үзләре дә сизмәстән, Таңчулпанның иң тирәнгә яшерелгән хис-тойгыларын казып чыгарырга тырышалар сыман иде.

– Әнә, урамда яңгыр коя,– дип куйды Фәндидә, әлеге бәхәсне икенчегә юнәлтергә теләгәндәй,– Кояш нурын күрер вакыт та бит…

Хәдичә аны шундук элеп алды:

– Изгелек белән бозыклык та кояш нуры белән яңгыр кебек. Тик изгелек нурына үзе теләгәннәр генә коена ала. Ә яңгыр үзе теләмәгәннәрне дә чылата.

Таңчулпан бер нәрсә дә әйтергә теләмәгән иде. Тик урамга карау белән бүген күргән төшен хәтерләде һәм үзе дә сизмәстән теге сүзне пышылдады:

– Бу – мәхәббәт яңгыры!

**2**

– Яздан бирле яңгыр яумаган иде, – дип куйды Егет бабай, тәрәзәгә бәргәләнгән яңгырга карап,– Кирәген бирә хәзер.

Искәндәр аңа гаҗәпләнеп карады:

– Ничек инде яздан бирле?

Бу юлы Егет бабай беренче кат күргәндәй аңа текәлде.

– Син нәрсә?—диде ул, озак кына шулай карап торгач,– Әллә чынлап та сизмәдеңме?

– Нәрсәне?

– Яңгыр булмаганны. Соң бөтен дөнья корылык килә дип чаң какты бит… Шаяртасыңдыр инде. Син сизмәгән нәрсә була мени!

Искәндәр дәшмәде. Егет бабай аңа караш ташлап-ташлап алды да үз эшенә тотынды. Искәндәрнең тел чарларга теләге юк, димәк, бик мөһим эше бар. Нинди нәрсә белән шогылләнгәнен сиздермәде сиздерүен дә, тик язган әйберсе үзенә ошаса, ул аны Егет бабасына укымый калмый инде. Менә мин нинди дигәндәй кинәнеп, хәтта бераз масая биребрәк укый әле ул аны. Егет бабасының фикерләрен дә бирелеп тыңлый, кайбер урыннарында бәхәсләшеп тә ала, ләкин, барыбер, ризалаша, кимчелекләрен төзәткән өчен рәхмәт әйтә, күңеле булганда: « Әлдә син бар әле!» – дип берәр коньяк та утырта. Тик язганының бер генә өтерен дә төзәтми, ничек булган – шулай калдыра. Әгәр нәрсәнедер үзгәртә башлый икән, аны бөтенләе белән, танымаслык итеп үзгәртеп куя. Яхшы якка, әлбәттә. Шул хакта берәр сүз әйтсәң, кул гына селти: «Һәй, мин төзәтә белмим шул… Баш төзәтә башласам да яңадан исерәм мин.» Шилма да малай инде. Егет бабай дигәне дә аннан чыкты бит. Эшкә килеп ике атна үтү белән:«Пенсия яшендә булсаң да бер тынгылык белмисең. Яшь егетләрдән болай чабасың. Егет бабай син. Чын-чынлап егет бабай»– диде дә… Зарифҗан бабасының исемен бөтенләй онытты, гел «Егет бабай»– дип эндәшә башлады. Аңа башкалар иярде. Шуннан китте инде… Әнә, бик бирелеп нидер укып утыра бит әле. Бер нәрсәне аңа укып күрсәтергә иде дә бит. Ярый инде, башка вакытка калдырырга туры килер. Бүленмәсен.

Гадәттә, бер казанга ике тәкә башы сыймый, диләр. Егет бабай белән Искәндәр, икесе дә абруйлы, танылган кеше булсалар да, бер-берсен бик ихтирам итәләр, вакыт-вакыт бәхәсләшеп, хәтта ачуланышып алсалар да, авырлык килгәндә бер-берсенә җил-яңгыр тидермәскә тырышалар иде. Менә өченче ел инде бер бүлмәдә, кара каршы утырып иҗат итәләр, иңгә-иң куеп яшиләр, моңа яшь аермасы да, икесенең дә горур җанлы, туры сүзле, вакыты белән хәтта аяусыз ачы телле булулары да комачау түгел.

– Таланты бар моның,– дип куйды кинәт Искәндәр, үзалдына сөйләнгәндәй. Аннан соң ниндидер бер горурлык белән дәвам итте, – Мондыйлар сирәк була. Әдәби әсәр язып караганы юк микән?..

Егет бабайның үзенә сәерсенеп төбәлгәнен күреп тертләп китте, алдындагы гәзит төпләмәсен ябып ук куйды. Бу уен кычкырып әйтергә теләмәгән иде ул.

– Нәрсә, үзебезнең гәзитне күргәнең юк идеме әллә?—дип мыек астыннан елмайды Егет бабай,– Кемнең талантына исең китте тагы?

– Дөресен әйткәндә, бик җентекләп укымыйм мин аны. Үзең пешергән ашны ничек ашамак кирәк?! – Искәндәрнең үтә җитди кыяфәте үзе бер мәрәкә иде,– Әле менә синең язмаларга күз йөгертеп чыктым. Бу килештән ничава егет күренәсең…

Егет бабай бүлмә яңгыратып көлеп җибәрде.

– Синең кебек остазым булганда сер биреп тормам инде,– диде ул Искәндәрнең шаяруын кабул итеп,– Ә үзең хәйран күзәтүчән икән…

Искәндәр дәшмәде. Өстәлдәге гәҗит төпләмәсен читкә этәреп куйды да бик эшлекле кыяфәт белән алдындагы кәгазгә текәлде. Аның шулай кинәт үзгәрүенә сагаеп калган Егет бабай бераз гаҗәпсенеп торды да, бүлдермим инде моны дигәндәй, кабат эшкә тотынды. Бүлмәдә тынлык урнашты. Озак вакыт буе, тәрәзәгә сибәләгән тамчылар астында, Егет бабайның ручкасы кәгазь буйлап йөгергәне генә ишетелеп торды.

Искәндәр бер нәрсә дә язмады, алдындагы ак кәгазьгә төбәлеп тораташ кебек каткан хәлдә тик утырды. Ул язарга уйлап та карамады, ул бөтенләй бер нәрсә хакында да уйламады, бары тик тәрәзәгә бәрелгән тамчылар җырын гына тыңлады. Ә яңгыр, йөрәк тибеше белән бер ешлыкка кереп, бары бер генә сүзне кабатлый иде:«Тамчы, там. Тамчы, там…» Шушы гади генә сүзләрдә Искәдәр өчен тирән мәгънә ятадыр сыман тоела, аның бөтен гомере шушы сүзләрнең ничек яңгырашына бәйледер төсле иде. Тамчы, там… Тамчы, там… Юк шул, гади генә сүзләр түгел шул бу… Аның нәрсә аңлатканын бер Искәндәр генә белә…

Бу халәтеннән аны Егет бабайның тавышы тартып чыгарды:

– Карале, син авырмыйсыңдыр бит?

Искәндәр бертын аптырап карап торды. Егет бабайның йөзендәге кайгыртучанлыкны күргәч кенә, сорауның мәгънәсе аңына барып җитте. Ул башта иңнәрен генә сикертеп куйды, азак бу хәрәкәтнең Егет бабайны борчуга салачагын уйлап, акланырга ашыкты:

– Юк инде, нинди авыру ди ул!..

– Көйсезрәк күренәсең… Үпкәләгән дисәм… Сине белмәсәм, уйлар идем инде…

– Баш эшләми менә…

Егет бабай сынап карап торды да көлемсерәп куйды. Аннан соң өстәл астыннан бер шешә аракы тартып чыгарды:

– Бәлки?

– Бәлки…—дип килеште Искәндәр,– Берәрне җибәрик, булмаса.

Рюмкаларга салып күтәрделәр.

– Бер сорау бар!—диде Искәндәр. Егет бабай игътибар белән тыңларга әзерләнде. Монда тост әйтешү урынына сорауга җавап биреп эчү гадәткә кергән иде. – Нәрсә ул мәхәббәт?

Егет бабай, шул да булдымы сорау дигәндәй, тәкәббер караш ташлап алды, тик шундук күзләрендә хыялый очкыннар балкып китте:

– Мәхәббәтме?!– ул бераз уйлангандай итте,– Мәхәббәт ул – бөтенесе дә!

Искәндәр тулырак, фәлсәфирәк, тапкыррак җавап көткән иде. Ләкин, төптәнрәк уйласаң, моннан да тапкыр сүзне табып була микән?! Мәхәббәт ул – бөтенесе дә. Шулай шул… Кызганычка каршы, шулай…

Егет бабай, Искәндәрнең үзе белән килешүен сизеп, канәгать елмайды да рюмкасын алгарак сузды:

– Хәзер минем чират. Син әйт менә – шигърият нәрсә ул?

Искәндәр уйга калды. Колагына янә яңгыр җыры килеп керде. Тамчы, там… Там-чытам… Тик бу хакта уйларга кирәкми иде, моннан арынырга, ераграк качарга теләп рюмка күтәрделәр түгелме соң?!.

– Шигърият ул мәхәббәт кебек, – диде Искәндәр, шаяруга күчеп,– Аны аңлап та, аңлатып та булмый…

Бу җаваптан канәгатьсезлеге Егет бабайның йөзенә үк чыккан иде. Хәзер ул ачы итеп, ник туганыңа үкенерлек итеп нәрсәдер әйтәчәк иде. Тик шуны гына көткән Искәндәр бик җитди кыяфәт белән фикерен төгәлләп куйды:

– Аның белән шөгылләнеп кенә була.

Егет бабай кычкырып көлеп җибәрде. Аннан соң рюмкасын чәкәштерергә сузды:

– Карале, синең дә баш эшли икән бит… Ярый, әйдә.

Рюмкаларны төпләп куйгач, бераз тын утырдылар. Гайрәтле урыс аракысы ашказанын рәхәт яндырып төшеп китте дә аның ләззәтле ялкыны бөтен тәнгә таралды. Мондый мизгелне сөйләшеп әрәм итү бер канунга да сыярлык түгел иде. Бераздан Искәндәр ике рюмканы да кулына алып, елмая биребрәк укырга тотынды:

– Беребез Сак булдык, беребез Сук булдык—

Ике алкашка кереп юк булдык…

Егет бабай моны өнәмәде:

– Сак-Сукка кагылма, – диде ул, катгый итеп,– Сак-Сук – тормыш гармониясе.

– Тормыш гармониясе аерылу-аймылышудан тора мени инде хәзер? Сак белән Сук кавышсалар яшәү тукталачак мени?

Егет бабай аңа:«Бүген тудыңмы әллә» дигән караш ташлады да уйчанланып дәвам итте:

– Көн бар – төн бар, ак бар – кара бар, мәгъриб бар – мәшрикъ бар, Сак бар —Сук бар… Аларның кавышуын син ничек күз алдына китерәсең?

Искәндәр телсез калды. Ул мондый җавап көтмәгән иде.

– Син кытайча фикер йөртәсең, – диде ул бераздан,– Җир-Күк, Ут-Су, Инь-Янь…

– Бер үк Җирдә яшибез, лабаса. Шуңа да Сак-Сук ул кытайның Инь-Яне кебек.

– Ләкин Сак-Сук ике бертуган бит…

– Менә шулай шул,—Егет бабай тантаналы елмайды,– Ике бертуганның кавышканын кайчан күргәнең бар?! Инсест – табу. Борын-борыннан. Ул гарип балалар тууына сәбәпче була.

– Бәлки, син хаклыдыр. Ләкин без бер нәрсәне оныттык. Ир белән Хатын дигәне дә бар бит әле.

Бу юлы Егет бабай уйга калды.

– Алар хакында да «кавышу» сүзен кулланалар, әлбәттә. Ләкин бу очракта ул образлы сүз буларак яңгырый. Ә асылда алар да көн белән төн кебек бер-берсен тулыландырып яши.

Искәндәрнең бирешәсе килмәде. Дөресен генә әйткәндә, бу нәрсәләрне ул күптән киптереп элгән иде инде, аның бөтенләй башка юнәлештә сөйләшәсе, Егет бабайның сүзләре аша үз уйларына, үз тойгыларына яклау табасы килә иде.

– Бер-берсен өзелеп яратып та бергә кала алмаган ярларны да Сак-Сук белән тиңлиләр бит әле.

Егет бабай аңа серле караш ташлады. Аннан соң шелтәле тавыш белән әйтеп куйды:

– Нәрсә өчен бу юк-бар сорау белән маташа әле, дип уйлаган идем аны. – Аннан соң беркавем тын торды,– Бездә эшлиме, әллә авторларыбыз арасыннанмы?

– Кем?

– Ярый, вакыты җиткәч, кем икәнен үзем әйтермен.

Егет бабай рюмкаларга аракы койды да Искәндәргә карады:

– Монысын тост әйтеп эчик әле, —диде ул, үтенгәндәйрәк итеп, Искәндәрнең баш кагуын күреп рюмкасын чәкәштерергә сузды – Әйдә. Гаиләләребезнең иминлеге өчен!

Озак кына дәшми утырдылар. Искәндәр инде тамчы җырын да тыңламады, хәмер тәэсире белән дә ләззәтләнмәде, ул бары тик бер генә нәрсә хакында баш ватты – үзе дә уйларга курыккан нәрсәне Егет бабай ничек сизде икән? Бу сорауга ул җавап таба алмаячак иде, бу сорауга җавап эзләү үз көчеңне юкка әрәм итү. Шуңа ул сүзне бөтенләй башка юнәлешкә борды:

– Карале, Егет бабай… Чынлап та яздан бирле яңгыр яумады мени?

Егет бабай елмаеп куйды:

– Бер дустым бар иде. Черниковкада яши бу, телецентрда эшли. Көн дә шул араны урый инде. Шул сөйли торган иде: «Малай, бер мәлне айнып китсәм, Октябрь проспектын төзеп бетергәннәр.» Теге кич кайтканда исерек була, йоклап кайта икән, иртән эшкә килгәндә – махмырдан, башын да күтәрерлек хәлдә түгел. Ә син соң… Исереп тә йөрмәдең бугай инде…

Искәндәр елмайды гына. Акбабай дәвам итте:

– Мин ул хакта бер нәрсә язган идем. Теләгең булса, сиңа укыйсым килә… – Искәндәрнең ризалык белдерүенә сөенеп, өстәп куйды,– Ләкин ул озын һәм… Ярый, укып карыйм әле…

Искәндәр тәүдә җиңел әйбердер дибрәк уйлаган иде, шуңа бик игътибар бүлеп бетермәде, ә соңыннан аны туктатып, яңадан укырга кушты. Үзе, аңламыйрак калган урыннары булса, соңрак иркенләп тикшерермен дип, сиздермичә генә диктоффонын кушып куйса да, һәр сүзгә диккать биреп тыңлый башлады. Егет бабай үзенә күрә бер канәгатьлек белән, шигырь сөйләгәндәй итеп укырга тотынды:

«Яздан бирле яңгыр яумады.

Җәйнең аяз кояшлы көннәре тәүдәрәк кешеләрнең күңеленә чиксез сөенеч алып килгән иде. Алар шәһәрнең шырпы кабыдай бертөрле йортларыннан табигать кочагына ташландылар, шул хозурда күңел ачып, балык тотып, су кереп рәхәтләнделәр, елга буйларында бала-чаганың чыр-чу килгәне белән аралашып гармун, гитара моңнары, төрле телләрдә җырлаган тавышлар туктаусыз ишетелеп торды, тәмле учак исләре ерак—еракларга таралып борыннарны кытыклады; шушы ямьле көннәрдә ярсызлар ярын тапты, мәңге бергә булырга вәгъдәләр бирештеләр, парлыларның бер-берсенә булган мәхәббәте тагы да арта төште, моңарчы эт белән мәче

кебек яшәгәннәре дә иркә сүзләр белән эндәштеләр, сөю назларына биреләделәр; кояш җиргә елмаеп караса, җир кояшка багып балкыды, бу көннәрдә кешеләр генә түгел, бөтен дөнья, бөтен галәм туй итә сыман иде. Ләкин тора-бара тоташ бәйрәмнәр арыта башлады, кешеләрнең күңелендәге яктылык тоныкланып калды, күңелләр генә түгел, хәтта үләннәр, хәтта яфраклар үзләренең соклангыч яшеллеген җуеп караңгылана барды, ә озакламый саргаеп, сәлперәеп, ачлыктан йончыган сабыйдай гарипләнеп калдылар. Җир кояшка карап елмаймады, ул үз тәне буйлап дәртле җырлар җырлап аккан гөрләвекләрне сагынды, гөрләвекләр сутын үз вакытында тиешенчә сеңдереп кала алмаганы өчен өзгәләнде, үзенең язгы ялгышларына үкенгәндәй, ялгыш кына сибәләп киткән ике-өч бөртек яңгыр тамчысын да комсызланып йотты, моны зур бәхеткә санап, атналар буена онта алмады, шул өч тамчы аның төшләренә керде һәм ул ләззәтле елмаеп уянды да әлеге бәхетнең бары тик төштә генә булуына әрнеп газапланды; әлеге газапларыннан арынырга теләп, ул елгаларны сыгып алырдай итеп кочты, сулар саегып, ярлар тараеп калды; судагы балыкларга һава җитмәде, алар кайнап торган тынчу дөньяларыннан котылырга теләп, ярга сикерделәр, ләкин судан башын сузу белән кояш нурларында кибеп шундук җан бирделәр; Җир яңгыр көтеп тилмерде, яңгыр аның өчен сөю назлары кебек кадерле иде, яңгыр аның өчен бердәнбер яшәү чыганагы иде; ул үзенең сөеклесен көткән гашыйк кебек, азатлыкны көткән тоткын кебек, үз бәхетен көткән мескен кебек күк йөзендә пәйда булыр кара болытларны көтте; әгәр бу мизгелдә аннан:«Нәрсә ул бәхет символы?» – дип сорасалар, ул ике дә уйламыйча:«Кара болыт!» – дип кычкырыр, моның белән генә дә тыелып кала алмас:«Бәхет ул – кара болыт! Кара болыт – бәхет ул! Шуны да аңламыйсыз мени соң?!.»– дип үртәлер шикелле иде…»

Егет бабайның ашкынулы тавышы, тәрәзәгә бәрелгән яңгыр тамчылары белән бергә үрелеп, әллә нинди сәер бер халәт тудыра иде. Кояш нурларыннан коргаксып бер тамчы суга, биялдәй кадәрле болытка тилмергән Җир. Инде атнага якын туктамый яуган яңгыр. Шушы капма каршылык, битарафлык пәрдәләрен ертып, әллә нинди уйларга этәрә…

Ләкин тойгылар тирәненә чумарга насип булмады. Ишек шакыдылар да секретарьша кыз керде:

– Егет бабай, сезне шеф чакыра.

Үз әсәренең тәэсиреннән айнып җитәлмәгән карт аңа аптыраулы караш ташлады, азак эшнең нәрсәдә икәнен аңлап алды да:

– Ярый, кызым, хәзер керермен,– дип урыныннан кузгалды.

Егет бабай чыгып бераз тору белән, ишек ачылып китте дә Алсуның башы күренде:

– Искәндәр, диктофоныңны биреп тор әле,– диде ул, бүлмәгә узып та тормастан, һәм сораганын аның кулында күрү белән коридорга эндәште,—Таңчулпан, мин таптым. Искәндәрдән алырсың…

Һәм кайдадыр китеп тә барды. Аның артыннан ук Таңчулпан керде. Ул бер сүз дә дәшмәде. Хәтта күтәрелеп тә карамады. Искәндәр дә ни дип әйтергә дә белми аптырады. Теленә бер юньле сүз, башына ипле фикер килмәде, бары тик йөрәгенең ярсып тибә башлавын тойды да, арка үзәгеннән ләззәтле ялкын узганын тойды. Диктофонны биргәндә, кулы Таңчулпанның бармак очларына тиеп киткәч, аяк астында җир убылгандай бер халәт кичерде, күз аллары томаланды, башы әйләнде. Ишек ябылган тавыштан гына бераз һушына килгәндәй булып, көчхәл белән урынына барып утырды. «Соңгы вакытта юньләп йокы да күргән юк,– дип уйлады ул, – Җитмәсә, аракы да күп эчелә. Ял итеп алырга кирәк. Ял кирәк. Юкса, бөтенләй аяктан егылуың бар…»

Ләкин бу уенның күз буяу, үз-үзен алдау өчен генә икәнен ул белә иде. Үз-үзеңне алдап яшәп булмый, иртәме-соңмы ачыктан-ачык танырга туры киләчәк. Барсын да. Әлеге халәтнең төн йокысы күрмәүдән түгел икәнен дә, Сак-Сукларны кавыштыру уе кайдан килгәнен дә… Барсын да танырга һәм дөреслекнең күзенә карап:«Яңгыр ул «тамчы, там»—дип җырламый бит… Ул «Таңчулпан» – дип җырлый!..» – дияргә туры киләчәк.

**3**

«Яздан бирле яңгыр яумады,»– дип кабатлады Таңчулпан.

Үзенә килгән кунак белән әңгәмәләшкәч, ул Искәндәрнең кассетасын да тыңлап караган иде. Хатын-кызның кызыксынучанлыгымы, әллә башка сәбәп беләнме, тик ул диктофон эчендә онытылып калган кассетаны тикшермичә түзә алмады. Искәндәр ниләр майтара икән? Нәрсә уйлый икән? Әңгәмәдәшләре белән ул ничек сөйләшә икән? Башта: «Бер-ике җөмләсен генә булса да, тавышын гына булса да ишетим,»– дип уйлаган иде. Магнит тасмасыннан Егет бабайның бик тә сәнгатьле итеп нәрсәдер укыганын ишеткәч, аны ахрынача тыңламый кала алмады. Тыңлады да… Егет бабай нәкъ менә Таңчулпан хакында язгандыр сыман тоелды. Ул да бит, яңгыр көткән Җир кебек нәрсәдер көтә, ялкыткыч бертөрлелек белән аккан тынчу көннәреннән ул да гарык булган бит. Ул хәтта үзенең нәрсә көткәнен дә белә, әмма бу турыда уйларга гына курка, уйласа, тотанаклы һәм тыныч, читтән караганда хәтта бәхетле дә булып күренгән дөньясы җимерелер дә яшәүенең бар мәгънәсе хәрабәләр астында калыр сыман тоела.

«Язгы ялгышлары өчен үкенгәндәй… Язгы ялгышлары өчен үкенгәндәй… Язгы ялгышлары өчен… Язгы ялгышлар…»

Кечкенә чагында ук үзсүзле, тискәре бала булган ул. "Киреләнүеңә түзелмичә урам уртасында бәргәләп алган чакларым да бар иде",– ди иде әнисе дә. Тора-бара мондый тискәрелеге басылды, ә менә үзсүзлелеге бетмәде. Хәер, моны начар сыйфатка исәпләмәде Таңчулпан, һәр эштә мөстәкыйль фикер йөртергә омтылу, һәр нәрсәгә үз карашың булу тискәрелек дип тә аталмыйдыр әле. Әнисе дә "тискәре" дип әрләштерсә дә, моны бары тик яратып кына әйтә иде бит. Таңчулпан үз кызын шулай битәрләгән кебек.

Унөч-ундүрт яшьлек чакларында көзгегә караган саен эче поша иде аның. Кечкенә буй, ябык кына гәүдә. Әллә нинди кирәкмәгән зур күзләр. Китапларда язылганча, зәңгәр, һич югы кара да түгел бит ичмасам, ә соры төстә, мәченеке диярсең. Шул рәвешле, һәр төшеннән гаеп табып, үз күңелен үзе имгәтә дә көннәр буена сыкранып йөри иде. Шулай да ахирәтләре, тиңдәшләре белән аралашканда болар бераз онытылып тора, чөнки Таңчулпанны барсы да ярата, үз итә, алар өчен кызның матурлыгы түгел, ә яхшы иптәш булуы мөһимрәк иде. Әнисе дә, аның күңел кичерешләрен аңлагандай, һәрдаим сөеп-иркәләп, аның озын чәчләренә, керфекләренә соклануын белдереп тора, ара-тирә:" Чынлап та шундый гүзәл кызмы бу, әллә үзем яратканга гына шулай тоеламы!"– дип әйткәләп тә ала иде. Ахирәтләренең үз итүен, егетләрнең дә сокланулы карашларын тоюданмы, әкренләп, әүвәлге кимсенүләре юкка чыкты, ул үзенең дә менә дигән гүзәл икәнлегенә ышана төште, бу ышану үз-үзенә ихтирамын, шәхеслек горурлыгын арттырды.

Ачык йөзле мөлаем кыз булды Таңчулпан. Шаянлыгы, шуклыгы да җитәрлек иде. Юк кына нәрсәләрне дә күңелле күренешкә әйләндерә белүе, котылгысыз күренгән хәлләрдән дә чыгу юлын тиз таба алуы белән дә аерылып тора иде. Шуңа да ахирәтләре арасында абруе зурдан булды, аларны үзенә аудару өчен бер нәрсә кылмаса да, кызлар Таңчулпанга тартылдылар, ярдәм сорап та, киңәш сорап та киләләр, аның белән дуслашуны абруйга саныйлар иде. Үсеп буй җиткергәч тә шулай дәвам итте. "Бер егет артымнан йөри, нишлим икән?"– дип тә килделәр, "Фәлән егеткә гашыйк булдым, ничек сиздерим икән?"—дип тә сер чиштеләр. Таңчулпан аларга бирәр киңәш биргәндер инде, тик ул мәхәббәт хисе белән таныш түгел иде. Китаплардан укып, кинолардан карап аның ләззәтле һәм изге тойгы икәнен чамаласа да, шуграк егетләр үзен озатырга маташуын күрсә дә, ул гашыйк булуның нәрсә икәнен дә беми иде әле. Әлбәттә, аралашып йөргән егетләреннән кайберләре аңа ошый һәм кыз алар белән аеруча яхшы могаләмәдә иде. Ләкин дөньяңны онытып гашыйк булырлык дәрәҗәдә түгел иде алар, буйга җитеп беренче һәм бердәнбер мәхәббәтен көткән кызның күңел таләпләренә дәва булырлык түгел иде.

Унынчыны тәмамлап, институтка керергә хыял корып йөри иде Таңчулпан. Мондый чакларда күңелеңне иләсләндереп, мәхәббәт хакында гына уйлап йөреп булмый, укырга, имти-

ханнарга әзерләнергә кирәк. Ләкин яшьлек китапка төбәлеп кенә яши алмый, дус-ишләрең белән аралашуны, күңел ачуларны да таләп итә. Һәм ул эшенә дә, укуына да, җилләнеп алуга да өлгерә. Шуңа да яшьлек бит ул.

Нәкъ әнә шул мәлдә классташ кызының абыйсы Ильяс армиядән отпусыга кайтып төште. Киткәндә чебеш кебек кенә бер малай иде, әле үсеп, тазарып кайткан. Кыска алынган кue кара чәчләре, атлетларча гәүдәсе, көч-гайрәт сирпеп торган хәрәкәтләре белән ул кино геройларын хәтерләтә иде. Клубка чыккач ул барсы белән дә кочаклашып күреште, кызларның бит очыннан үбеп тә алды. Тик Таңчулпанны күргәч кенә ничектер сәерләнеп катып калды, утлы карашларын кыздан ала алмый торды. Таңчулпан кызарды, хәтта колакларына кадәр кызган тимер төсенә кергәндәй тоелды. Күкрәгендә нәрсәдер тертләп өзелгәндәй булды, йөрәге ашкынып типте. Моның нәрсәдән икәнен дә аңламады кыз. Бу халәт аңа таныш түгел иде. Кичке уеннардан соң ахирәте һәм Ильяс белән бергә кайттылар. Таңчулпан бик сөйләшмәде. Ә кереп урынга яткач, төне буе күзен йоммады. Күңелдә әйтеп аңлата алмаслык рәхәтлек тә, газап та, курку-шикләнү дә тагы әллә нинди тойгылар бергә буталып утлы өермә куптарды. Ул өермәнең ялкын телләре иркәли дә, яндыра да кебек иде. Аның, берчә, галәм яңгыратып көләсе, берчә, тәгәрәп ятып елыйсы килде. Күз алдыннан Ильясның утлы карашлары, колак төбеннән тавышы китмәде.

Таңчулпан гашыйк иде.

Ә икенче көнне Ильяс аны озатып куйды. Капка төбенә җиткәч, озак кына сөйләшеп тордылар. Нәрсә хакында?– монсын хәтерләми кыз, ул күңелендә кайнаган хисләр тәэсиреннән ни тере, ни үле бер халәттә иде. Егетнең куллары биленә кагылгач, бөтенләй таралып киткәндәй булды. Иреннәр иренгә кушылды… Рәхәт иде кызга, тик ниндидер курку катыш бер тойгы бу халәттән котылуны таләп итте. Таңчулпан ирексездән башын читкә борды, аннан соң куллары белән егетнең күкрәгенә таянды.

–Җитәр, кирәкми…

– Кирәк!– Ильяс аны куенына алмакчы булган иде, кызның каты торуын күреп тыелып калды.

Имтиханнар кайгысы китте Таңчулпаннан, нәрсәгә генә тотынса да Ильяс хакында уйлады. Уйлары каршылыклы иде. Берчә, үзенең тәүге очрашуда ук кочаклатып-үптереп торуы өчен гарьләнде, аны йомшак кызга исәпләр дә бүтән борылып та карамас дип курыкты, берчә, капка төбендә озаграк тормавына үкенде.

Ильяс икенче көнне дә, өченче көнне дә килде… Урамнарда, яланнарда йөрделәр. Баштагы күңел давылы гомер буе дәвам итәр кебек тоелса да тора- бара тына башлады. Таңчулпан Ильясны көтеп ала, аның янына шатланып чыга иде. Тик инде егет хакында көннәр буе уйланып йөрмәде, язгы елга булып ташкан хисләр кабат үз ярына кайтты. Кабат хәрби хезмәткә китәр алдыннан Ильясның: "көтәрсеңме?"– дигән соравына уңай җавап бирсә дә үз сүзенә үзе дә бик ышанып җитмәде. Амияга киткәч, егетнең хатлары бер-бер артлы агылып кына торды. Алар Таңчулпанның күңеленә назлы бер рәхәтлек өсти иде. Ләкин кыз үзе язарга бик ашыкмады, икенең берсенә генә җавап бирде. Үз хәлен үзе дә аңламады ул, Ильяс аңа шул тиклем якын да, шул кадәр ят та кебек иде. Нишлисең, мәхәббәт шулай буладыр инде. Ильяс армиядән кайтып яңадан очраша башласалар, хисләре дөрләп кабынып әле.

Авылда да, институтка укырга кергәч тә артыннан йөрүче егетләр аз булмады. Тик Таңчулпан берсен дә иямләштермәде аларның. Хәер, күрше авылдан Тәлгать ябышып диярлек йөргән иде, берничә тапкыр озатып та куйды. Ә кыз нишләсен, тукмап озата алмый ич. Капка төпләренә җиткәч, беренче уңайлыктан ук файдаланып, өйләренә сыпырта иде. Юк, тиргәшмәде дә, кыргыйланмады да ул, ни дисәң дә Тәлгать начар егет түгел иде, чибәрлеге дә бар, тәртипле дә. Таңчулпанның Тәлгатькә исе китмәвен күреп, ахирәтләре шелтәләп тә алгалады:

–Менә дигән егет бит. Җитмәсә, колхоз рәисенең улы. Аңа кияүгә чыксаң, балда-майда гына йөзәчәксең.

Әлбәттә, хәерчелектә гомер итәсе килми иде кызның. Бай кешенең баласы кем булса да ярлылыкта интекми ул. Аннан соң яратышып өйләнешеп тә озак яшәмәгән гаиләләр авылда да хәтсез генә. Ахирәтләре бу яклап хаклы иде, әлбәттә. Әйбәт кеше белән бергә яши-яши мәхәббәт тә килергә мөмкиндер әле ул. Тик Таңчулпан Тәлгать белән йөрергә үзен мәҗбүр итә алмады. Әнисенең сүзләре дә колагына кергәндер инде.

– Байга түгел, яраткан кешегә чыгарга кирәк,– ди торган иде ул,– Аның мөлкәте, барыбер, синеке булмый. Бергә тапкан мал гына кадерле була ул. Алтын сарайда тоткын булганчы, гади ояда асылкош булганың.

Ильяс кайткач, чынлап та, хисләр яңадан кабынды. Авылда да еш очраштылар, егет шәһәргә дә килеп йөреде. Кызның кичерешләре беренче кат очрашкандагы кебек гөлтләп китмәсә дә Ильяска ул битараф түгел иде. Ләкин егет тора-бара үз кадерен үзе җибәрә башлады, эчеп тә килгәли, сөю-назлауларны тирәнгәрәк җибәрергә теләп тә бимазалый. Тик иң үзәккә үткәне сәбәп табып та, бер сәбәпсез дә көнләшеп җан ашавы булды. Ильяс сүз әйтмәсен дип бер егет белән дә сөйләшмичә тора алмый ич инде Таңчулпан. Аның көнләшүе институтка имтихан тапшырып та укырга керәлми кайткач, отыры ныгак көчәйде. Артык нык яратуданмы, әллә үз-үзен кимрәк санаудан идеме бу, белмәссең. Бәлки, икесе дә булгандыр. Авылга кайткан чакларында:

– Җибәрмим Уфаңа! Егетләр белән буталмыйсың! Миңа кияүгә чыгасың!– дип этләгән чаклары да аз булмады.

Таңчулпан инде аның белән кабат очрашмау турында да уйлана башлаган иде, тик "бәлки, гомер буе шулай булмас, төзәлер, акылга килер"—дигән өмете моңа ирек куймады. Ни генә әйтсәң дә, Ильяска булган хисләре сүнеп бетмәгән иде әле. Бу хәл, бәлки, озак дәвам итәр һәм Таңчулпан аңа кияүгә дә чыгып куяр иде, әмма бер көнделсез хәл бөтенесен дә кинәт үзгәртте.

Ул көнне тулай торак бүлмәсендә бергә яшәгән бер ахирәтенең туган көне иде. Егетләр, кызлар табын корып бергә җыелышып күңел ачтылар, җырладылар, биеделәр. Өстәлдә аракы, шәраб та бар иде, шуңадырмы, һәркемнең кәефе күтәренке булды. Мәҗлес ахырына җитеп килгәндә ишек тукылдаттылар. Бу Ильяс иде. Таңчулпанны чакырып кына чыгарды да исәнлек-саулык та сорашып тормастан, җикеренергә тотынды:

–Син.. Фәхишә… Бордель оештырып ятасыңмы?! Күтләк!..

Якын кешесеннән мондый сүзләр ишетүдән Таңчулпан еларга да, ачуланырга да белмәде. Егетнең сүгенүе тагы да ямьсезрәк төс ала башлагач, кинәт килгән ярсу белән, аның яңагына чабып җибәрде. Ильяс һушына килер дә гафу үтенер дип көткән иде. Ләкин нык ялгышты. Егет үзе дә аны шанлап җибәрде һәм якасыннан алып стенага кысты:

– Син… Сөйрәлчек… Минем алда саф булып кыланасың… Бел, үземнеке итәм, барыбер. Тотып эшлим мин сине!

һәм кыз аны-моны уйлап өлгергәнче, китеп тә барды. Таңчулпан юыну бүлмәсенә кереп туйганчы елады. Моңа кадәр беркемнең дә аны болай мәсхәрәләгәне юк иде әле.

Тынычланып бүлмәгә кергәндә мәҗлес тәмамланган иде инде. Егете белән бер ахирәте генә калган. Тиздән алар да киного дип чыгып китте. Авыр уйлардан арынырга теләп, кыз телевизорны кабызды, тик бер юнле нәрсә дә юк иде. Әнә шулай нишләргә белми утырганда кинәт ишек ачылып китте дә анда Ильяс пайда булды. Ул керү белән бүлмәне бикләп куйды.

– Менә вакыты килеп тә җитте,– дип ыржайды ул, авызыннан аракы исе беркетеп һәм җан өшеткәч кискенлек белән өстәде,—Чишен!

Таңчулпан аны-моны уйларга өлгергәнче, изүеннән алып кофтасын ертып төшерде.

– Чишен, кәнтәй!

Кызның күңелендә нindидер кыл өзелгәндәй булды, бөтен тәнен чемердәтеп ачы салкын үтте.

– Башкаларга бирәсең бит… Нәрсә, кыланып торасың… Ильяс аңа янә сугып җибәрде дә кош баласын күтәргән җиңеллек белән караватка ыргытты.

– Кит, Ильяс… Сантыйланма… Син бит исерек…

Ниндидер мескенлек белән әйтелгән бу сүзләр егетне тагы да ныграк котыртты гына, ул Таңчулпанның өстенә ташланды.

– Мәңгегә дә сиңа буласым юк, – дип шыңшыды кыз, нәфрәтенә тончыгып, – Мәңгегә дә…

– Ә мин сине барыбер…

Егет сүзен әйтеп бетермәде, Таңчулпан аны беләгеннән умырып тешләп алды. Ильяс ыңгырашып куйды һәм икенче кулы белән кызның яңагына тондырды. Нәкъ шул вакытта ишек шакыдылар.

– Ярдәм итегез, ярдәм…– Таңчулпан бөтен көченә кычкырды, тик егетнең сугуыннан сүзе өзелеп калды.

Тагын ишек шакыдылар. Бу юлы катырак итеп. Тагын. Тагын. Кинәт ишек келәсе шартлап ычкынды да бүлмәгә егете белән ахирәте килеп керде. Ильяс шундук сикереп торды да егеткә сугып җибәрде, тегесе моны көтмәгән иде булса кирәк, караватка егылды.

# Конец ознакомительного фрагмента.

Текст предоставлен ООО «ЛитРес».

Прочитайте эту книгу целиком, купив полную легальную версию на ЛитРес.

Безопасно оплатить книгу можно банковской картой Visa, MasterCard, Maestro, со счета мобильного телефона, с платежного терминала, в салоне МТС или Связной, через PayPal, WebMoney, Яндекс.Деньги, QIWI Кошелек, бонусными картами или другим удобным Вам способом.